КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 15 сентябрь г.Казань № 697

«Татарстан Республикасы яшьләренә психологик ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәне раслану турында

«Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 пунктының 3 өлеше, «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 10 өлеше, 7 статьясындагы 1 пунктының 3 өлеше, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 елның 11 июлендәге 563 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3 пунктындагы 8 пунктчасы нигезендә, авыр тормыш хәлендә калган яшьләргә ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасы яшьләренә психологик ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы (алга таба – Система) турындагы нигезләмәне расларга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгын – Системаның функциональ заказчысы итеп;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгын – Системаның функциональ операторы итеп;

«Яшьләр, инновация һәм профилактика программалары буенча «Навигатор» республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен – Система операторы итеп;

«Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесен – Системаның техник операторы итеп.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәкләренең муниципаль биремендә, Системаны кулланып, психологик ярдәм күрсәтүне кертүне;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә Система эшчәнлеге турында мәгълүмат биреп торуны гамәлгә ашыруны.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 15 сентябрь, 697 нче
карары белән расланды

«Татарстан Республикасы яшьләренә психологик ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы турында нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасы яшьләренә психологик ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы (алга таба – Система) эшчәнлеген тәэмин итү тәртибен билгели.

1.2. Системаны булдыру һәм эксплуатацияләү максаты – Татарстан Республикасында яшьләрнең бушлай квалификацияле психологик ярдәмнән файдалану мөмкинлекләрен арттыру (алга таба – психологик ярдәм).

1.3. Система Татарстан Республикасы мәгълүмат системаларының бердәм реестрына теркәлгән. Мәгълүмат системасы коды – 10.16.Г05.06.М00.00.00.077.

1.4. Системаның төп бурычлары:

видео-конференц-элемтә (алга таба – ВКЭ) форматында индивидуаль консультацияләр бирү юлы белән психологик ярдәм күрсәтү, шул исәптән агрессив үзтотыш куркынычы, депрессив халәтләр, суицид булган очракларда психологик ярдәм күрсәтү;

социаль имин булмаган хәлләрне, яшьләргә карата кырыс мөгамәлә һәм көч куллану очракларын ачыклау;

яшьләр арасында девиант тәртипне профилактикалау;

психологик ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән яшьләрнең коммуникатив компетентлыгын, психологик өлгергәнлеген һәм психологик тотрыклылыгын арттыруга юнәлдерелгән аң-белем бирү эшләре;

психологик ярдәм күрсәтү ысулларын киңәйтү.

1.5. Системаның эшләве түбәндәгеләргә шартлар тудыра:

психологик ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән программаларны һәм проектларны гамәлгә ашыруда ярдәм һәм булышу күрсәтүгә;

психологик ярдәм күрсәтүче психологларның эш графигын төзүгә;

психологик ярдәм күрсәтүгә кирә торган заявкаларны исәпкә алуга;

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 10ысына кадәр, Система операторы адресына әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасында бирелгән форма буенча Система эшчәнлеге турында хисап тапшыруга.

## II. Системада катнашучылар

2.1. Системада катнашучылар:

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы – Системаның функциональ заказчысы;

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы – Системаның функциональ операторы;

«Яшьләр, инновация һәм профилактика программалары буенча «Навигатор» республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе – Система операторы;

«Татарстан Республикасының Цифрлы трансформация үзәге» дәүләт казна учреждениесе – Системаның техник операторы;

психолог – югары психологик белемле һәм психологик ярдәм күрсәтү өчен җаваплы учреждениеләрдә психологик ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән һөнәри эшчәнлек гамәлгә ашыручы физик зат;

файдаланучы – Татарстан Республикасында яшәүче, психологик ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән 14 яшьтән 35 яшькә кадәр физик зат.

2.2. Системаның функциональ заказчысы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

психологик ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән эшчәнлек оештыруны;

Системаның эшен оештыруны;

федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының рәсми сораулары буенча Система эшчәнлеге турында мәгълүмат әзерләүне;

Системаның эш сыйфатын контроль тотуны.

2.3. Системаның функциональ операторы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Системаны «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесенең сервер җиһазында урнаштыруны;

Системаның эшләве өчен кирәкле сервер җиһазының һәм инфраструктураның өзлексез эшләвен тәэмин итүне;

«Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Системадан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өчен техник элемтә чаралары эшләвен.

2.4. Система операторы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

«Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Система сайтын булдыруны һәм аның эшләвен (алга таба – Система сайты);

«Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Telegram чат-ботын булдыруны һәм аның эшләвен;

психологларның психологик ярдәм күрсәтүен оештыруны һәм контрольдә тотуны;

Системаның оештыру, норматив һәм методик тәэмин ителешен;

Системада катнашучылар эшчәнлеген координацияләүне һәм Система сайты эшләве өлешендә алар арасында оператив үзара бәйләнешне;

Системаны үстерүгә техник таләпләр һәм (яки) техник биремнәр әзерләүне;

психологларның һәм файдаланучыларның Системадан файдалану мөмкинлеген;

Системаның эш нәтиҗәлелеген мониторинглауны;

психологларның психологик ярдәм күрсәтү турындагы заявкаларны үз вакытында эшкәртүен мониторинглауны;

Системаның функциональ заказчы адресына Системаны үстерү турында тәкъдимнәр җибәрүне.

психологларга, шул исәптән Татарстан Республикасы балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм үзәкләренең рәсми соравы буенча укулар оештыруны.

2.5. Системаның техник операторы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Системаның өзлексез эшләвен;

Системаны эксплуатацияләүгә һәм аның эшләвен тәэмин итеп торуга, шулай ук техник чараларга, элемтә каналларына, Системада эшкәртелә торган мәгълүматны саклауның техник һәм программа чараларына карата техник таләпләр һәм (яки) техник биремнәр әзерләүне;

техник (шул исәптән эксплуатация) документация таләпләре нигезендә Системаның программа тәэминаты эшләвен;

мәгълүмат куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча Россия Федерациясе законнары таләпләрен исәпкә алып, Системаның мәгълүматлар базаларында бирелгән мәгълүмат сакланышының мәгълүмати иминлеген;

Система функцияләреннән, Системада урнаштырылган белешмә, материаллардан файдалана алу мөмкинлеге хокукларын чикләү буенча рольле модельне кулланып, Системада катнашучыларның файдалана алу хокукын чикләүне;

масштаблау мөмкинлеге белән Системада урнаштырылган белешмәдән, материаллардан файдалану мөмкинлегеннән берничә файдаланучы куллана торган режим булуны;

Системада катнаушчыларның Системадан файдалану фактлары турында белешмәне теркәү һәм аларны саклауны гамәлгә ашыру, шул исәптән Системада гамәлләр кылу вакыты, мондый затларның исәпкә алу язулары һәм әлеге гамәлләр кылынган автомат сервислар турында мәгълүмат теркәлә торган Система функцияләренә карата Системаны алып баруны гамәлгә ашыручы органнар затларының гамәлләрен исәпкә алу буенча электрон журналны автомат алып баруны;

Системада урнаштырылган белешмәнең, документларның, материалларның, шулай ук программа чараларының резерв күчермәсен алу, аларны саклау һәм Системаның эшкә сәләте бозылганнан соң иң күбе 24 сәгать эчендә яңадан торгызуны;

Системаның сервер җиһазын һәм программа тәэминатын эшкә сәләтле хәлдә тоту буенча башка чараларны.

2.6. Психолог түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Психологның этика кодексы үтәлешен;

Россия Федерациясе территориясендә файдалану мөмкинлеге булган ВКЭ сервислары ярдәмендә әлеге рәсми сорау алынганнан соң 24 сәгать эчендә психологик ярдәм күрсәтүгә рәсми сорау алганда сылтама булдыруны һәм файдаланучыга әлеге сылтаманы психологның Системадагы шәхси кабинеты аша җибәрүне;

психологик ярдәм күрсәтүне;

әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасында бирелгән форма буенча психологик ярдәм күрсәтелгәннән соң 24 сәгать эчендә Системада психологик ярдәм күрсәтелү турында хисап тутыруны һәм аны Система аша Система операторы адресына җибәрүне;

ай саен, айның 20сенә кадәр, Системага психологик ярдәм күрсәтү графигын кертүне.

2.7. Файдаланучы түбәндәгеләрне тәэмин итә:

Системада урнаштыру өчен җибәрелә торган белешмәләрнең, материалларның дөреслеген, тулылыгын һәм актуальлеген;

психологик ярдәм күрсәтү кысаларында психолог белән үзара ачык итеп хезмәттәшлек итүне.

## III. Системаның эш тәртибе

3.1. Система аның эшчәнлеген, Системада катнашучыларның вәкаләтләрен башкару мөмкинлеген һәм файдаланучылар өчен Системада урнаштырылган мәгълүматларга, материалларга керү мөмкинлеген тәэмин итә торган түбәндәге компонентлардан тора:

мәгълүмати лендинг;

файдаланучының шәхси кабинеты;

психологның шәхси кабинеты;

Telegram чат-боты.

3.2. Мәгълүмати лендинг психологик ярдәм алу мөмкинлекләре турында статик мәгълүматны күрсәтү өчен билгеләнгән.

3.3. Файдаланучының шәхси кабинеты психологик ярдәм күрсәтелүгә язылулар белән идарә итү һәм кире элемтә булдыру өчен билгеләнгән.

3.4. Психологның шәхси кабинеты психологик ярдәм күрсәтүгә заявкалар белән идарә итү өчен билгеләнгән.

3.5. Telegram чат-бот файдаланучыларны теркәү һәм Telegram кроссплатформалы системасын кулланып психологик ярдәм күрсәтүгә заявкалар бирү өчен билгеләнгән.

## IV. Система кысаларында мәгълүмати үзара хезмәттәшлек

4.1. Системада катнашучылар арасында мәгълүмат алмашу электрон формада башкарыла һәм Система аша файдаланучының соравы буенча ВКЭ режимында индивидуаль консультацияләр бирү юлы белән психологик ярдәм күрсәтү күздә тотыла.

4.2. Системаның функциональ заказчысына һәм операторына Системаның белешмәләреннән һәм материалларыннан файдалану мөмкинлеге бирелә.

4.3. Белешмәләрне һәм материалларны Системага урнаштыру, шулай ук аларны теркәү һәм исәпкә алу Система операторы тарафыннан электрон рәвештә гамәлгә ашырыла.

4.4. Файдаланучыларның Системада урнаштырылган белешмәләрдән һәм материаллардан файдалану мөмкинлеге, түләү алмыйча, Система сайтыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

4.5. Системада катнашучыларның мәгълүмати һәм технологик үзара хезмәттәшлеге аларны программалы һәм технологик инфраструктура аша интеграцияләү, катнашучылар һәм Система операторы арасында белешмәләр һәм материаллар алмашу нигезендә электрон рәвештә рәсми сораулар җибәрү һәм җаваплар алу юлы белән башкарыла.

«Татарстан Республикасы яшьләренә психологик ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасы яшьләренә психологик ярдәм» Татарстан Республикасы
дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасының кварталлык эшчәнлеге турында
хисап

| | |
|---|---|
| Консультация форматы | |
| Психологик ярдәм күрсәтүче үзәкнең тулы һәм кыскартылган исеме | |
| Психологның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда) | |
| Психологның элемтәгә керү өчен кәрәзле телефон номеры | |
| Системада психологлар җәлеп ителде | |
| Планлаштырылган консультацияләр сәгатенең гомуми саны | |
| Заявкалар керде | |
| Карауда | |
| Планлаштырылды | |
| Консультацияләр үткәрелде | |
| Файдаланучы тарафыннан баш тартылды | |

| Эшкәртелмәгән заявкалар (хисап тутыру вакытына) | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Барлыгы консультацияләр бирелде | | | | | | | | | | | | | | |
| Коды | Мөрәҗәгатьләр кодификаторы | «Татарстан Республикасы яшьләренә психологик ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасына мөрәҗәгатьләр керде | | | | | | | | | | | | |
| | | барысы | ир-атлар | хатын-кызлар | мөрәҗәгать итүчеләрнең яшь категориясе | | | | | | | | балигъ булмаганнарның ата-аналарыннан, законлы вәкилләреннән мөрәҗәгатьләр керде | |
| | | | | | 14 яшьтән 17 яшькә кадәр | | 18 яшьтән 24 яшькә кадәр | | 25 яшьтән 35 яшькә кадәр | | башка гражданнар | | | |
| | | | | | ир-атлар | хатын-кызлар | ир-атлар | хатын-кызлар | ир-атлар | хатын-кызлар | ир-атлар | хатын-кызлар | ир-атлар | хатын-кызлар |
| 1. | Теләсә нинди мөнәсәбәтләрнең нигезе буларак бәйлелек | | | | | | | | | | | | | |
| 2. | Психологик травмалар | | | | | | | | | | | | | |
| 3. | Депрессия, төшенке кәеф | | | | | | | | | | | | | |
| 4. | Эш, уку һәм шәхси нәтиҗәлелек | | | | | | | | | | | | | |
| 5. | Когнитив һәм эмоциональ кыенлыклар | | | | | | | | | | | | | |
| 6. | Партнерлар белән мөнәсәбәтләр | | | | | | | | | | | | | |
| 7. | Гомумән кешеләр белән мөнәсәбәтләр | | | | | | | | | | | | | |
| 8. | Башка | | | | | | | | | | | | | |
| | Барлыгы | | | | | | | | | | | | | |

«Татарстан Республикасы яшьләренә психологик ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасы турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта

Форма

«Татарстан Республикасы яшьләренә психологик ярдәм» Татарстан Республикасы дәүләт автоматлаштырылган мәгълүмат системасында күрсәтелгән психологик ярдәм турында
хисап

| | |
|---|---|
| Файдаланучының исеме | |
| Файдаланучының туган көне | |
| Мөрәҗәгать итү датасы | |
| Мөрәҗәгать темасы | |
| Консультация тибы | |
| Аналитика | |

_______________________________